| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2024 ел Баулы шәһәре №150

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 декабрендәге 238 номерлы карары белән расланган, 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча Комплекслы программага (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 11 мартындагы 45 номерлы, 2022 елның 5 декабрендәге 253 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 декабрендәге 238 номерлы карары белән расланган, 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча Комплекслы программага (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 11 мартындагы 45 номерлы, 2022 елның 5 декабрендәге 253 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

VII «Программа чаралары» бүлегендә:

7.3. пунктында «3-нче мәсьәлә: Җәмәгать иминлеген тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлеген оештыру һәм җәмәгать урыннарында хокук тәртибен һәм иминлекне тәэмин итү һәм җинаятьләрне ачу өчен заманча техник чаралар кертү»:

- 3.6. пунктчасында «ТР БМР бюджет акчалары исәбеннән финанслау, бюджеттан тыш чыганаклардан һәм башка чыганаклардан акчалар (мең сум)» графасында, «2024» графасы астындагы «192,443» саннарын «189,559» саннары белән алмаштырырга;

- «3-нче мәсьәлә буенча йомгаклау» юлында, «ТР БМР бюджет акчалары исәбеннән финанслау, бюджеттан тыш чыганаклардан һәм башка чыганаклардан акчалар (мең сум)»

графасында, «2024» графасы астындагы «225,268» саннарын «222,384» саннарына алмаштырырга;

«Программа буенча йомгаклау:» юлында:

- «ТР БМР бюджет акчалары исәбеннән финанслау, бюджеттан тыш чыганаклардан һәм башка чыганаклардан акчалар (мең сум)» графасында, «2024» графасы астындагы «1418,468» саннарын «1415,584» саннары белән алмаштырырга;

- «7330,951» йомгаклау саннарын «7328,067» саннары белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров